РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» июля 2024 ел г. Альметьевск № 2429

Әлмәт муниципаль районы Башкарма
комитетының «Бинаны торак урыны,
торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы
йортны авария хәлендә һәм сүтелергә
яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча
йортын торак йорт һәм торак йортны
бакча йорты дип тану буенча ведомствоара
комиссия турында» 2021 елның
12 гыйнварындагы 01 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия турында» 2021 елның 12 гыйнварындагы 01 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 октябрендәге 1506 номерлы, 2022 елның 16 маендагы 896 номерлы, 2022 елның 1 июлендәге 1328 номерлы, 2022 елның 9 ноябрендәге 2587 номерлы, 2023 елның 02 июнендәге1713 номерлы, 2023 елның 13 декабрендәге 7858 номерлы, 2024 елның 7 маендагы 1701 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә:

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«12» гыйнвар 2021 ел № 01
карары белән расланган
1 нче кушымта

Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия составы

заказ № 1-851

Сәлимгәрәев И.И. - комиссия рәисе, район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары;

Салмина О.В. - комиссия секретаре, район Башкарма комитетының торак фонды белән идарә итү бүлеге башлыгы.

Комиссия әгъзалары:

Бикчәнтәева Л.З. - Әлмәт зональ торак инспекциясе башлыгы (килешү буенча);

Насыйбуллин И.Г. - Әлмәт муниципаль районының архитектура бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы;

Носова О.Г. - «Үсеш департаменты» муниципаль автоном учреждениесе директоры урынбасары (килешү буенча);

Лаптева С.В. - «Татарстан Республикасының техник инвентаризация бюросы» АҖнең Әлмәт филиалы директоры (килешү буенча);

Узаков М.К. - Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Әлмәт районындагы һәм Әлмәт шәһәрендәге Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча);

Украинская Ю.И. - Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты рәисенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге һәм төзелеш мәсьәләләре буенча урынбасары (килешү буенча);

Хәйруллина И.В. - Әлмәт, Зәй, Лениногорск һәм Сарман районнарында Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең территориаль бүлеге башлыгы (килешү буенча).

Торак урын милекчесе (ул вәкаләт биргән зат) комиссиядә киңәш бирү тавышы хокукына ия эшкә җәлеп ителә һәм комиссия утырышының вакыты һәм урыны турында Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы яисә комиссияне төзегән җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә хәбәр ителергә тиеш.

Эксперт билгеләнгән тәртиптә проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык тикшеренүләренә экспертиза нәтиҗәләрен әзерләү хокукына аттестацияләнгән.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары И.И. Сәлимгәрәевка йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларны башкаручы А.Р. Исхаков